ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БИШНИНСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЗЕЛЕНОДОЛЬСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, 5, с.Бишня,
Зеленодольский район, 422528

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗЕЛЕНОДОЛЬСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БИШНЭ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Центральная ур., 5, Бишнэ ав,
Зеленодольск районы.,
422528

---

**КАРАР**

2017 елның 28 ноябре №19

Бишнә авыл җирлегенең азкатлы шәхси торак төзелеше территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Каты көнкүреш калдыкларын чыгару буенча хезмәтләр күрсәтү Кагыйдәләрен раслау турында»гы 1997 елның 10 февралендәге 155 номерлы Карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Торак һәм коммуналь хезмәтләр күрсәткәндә халыкның хокукларын һәм мәнфәгатьләрен яклау системасының нәтиҗәлелеген арттыру чаралары турында»гы 2010 елның 19 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә һәм инфекцияләр таралуны булдырмау һәм экологик хәлне яхшырту максатларында чисталыкны тәэмин итү өчен,

**карар итәм:**

1. Тәкъдим итәргә:

1.1. Югарыда күрсәтелгән территориядәге милекнең оештыру-хокукый формасына карамастан, оешмаларга, шулай ук Бишнә авыл җирлегендә азкатлы төзелеш территориясеннән чүп чыгару буенча хезмәт күрсәтүче шәхси эшмәкәрләргә югарыда күрсәтелгән территориядә яшәүче кулланучылар белән килешүләр төзергә.

1.2. Килешү төзегәндә каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү буенча хезмәт күрсәтү бәясе кешегә аена 53,50 сумнан артмаска тиеш.

1.3. Теркәлгән гражданнар булмаган очракта, Бишнә авыл җирлегенең азкатлы торак йортларыннан каты көнкүреш калдыкларын җыю, чыгару һәм утильләштерү буенча хезмәт күрсәтү бәясе хуҗалыктан аена 53,50 сумнан артмый.

2. Бишнә авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесенең «Бишнә авыл җирлегенең азкатлы шәхси торак төзелеше территориясеннән каты көнкүреш калдыкларын чыгару турында» 28.11.2016 ел, № 39 карары үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2018 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. Әлеге карарны «Яшел Үзән» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында

(http://pravo.tatarstan.ru) һәм Зеленодольск муниципаль районының Рәсми сайты составында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук җирлекнең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

**Бишнә авыл**
**жирлеге башлыгы** **И.М.Фатхуллин**